ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 9 » декабрь 2016 ел № 1284

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыру турында**

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Россия Федерациясенә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 26 октябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1.Расларга:

-даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирү (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс документациясен (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру таләпләрен (3 нче кушымта);

-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы (4 нче кушымта).

2. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салынмый торган тарифлар буенча ачык конкурс заказчысы, Арча муниципаль районы башкарма комитеты, ачык конкурсны оештыручы - Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан билгеләнә.

3. Арча муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрүне тәэмин итәргә. 2012 елның 1 гыйнварына кадәр

4. Конкурс үткәрү турындагы хәбәрне (5 нче кушымта) Арча муниципаль районының рәсми сайтында www.arsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.Е. Спичкинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин